**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «КОМСОМОЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«02» июля 2021 ел № 11/2

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 27 мартындәге 2/2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милегендә булган җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 январендәге 7-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы « Комсомол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 27 мартындәге 2/2 номерлы карары белән расланган (2021 елның 12 февралендагы 5/2 номерлы карар үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милегендә булган җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.2.2, 2.4, 3.3.1 – 3.3.7, 3.5, 3.14, 3.16 һәм 3.17 пунктларын төшереп калдырырга;

2) 2.3 пунктында «милекчеләре» сүзен төшереп калдырырга;

3) 2.6 пунктында «Җир кишәрлеген сайлау акты,» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 3.2 пунктына түбәндәге эчтәлектәге өченче җөмләне өстәргә:

«Рөхсәт бирү тәртибе авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән расланган Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында билгеләнә.»;

5) 3.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Рөхсәт бирү гариза бирүченең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычы булмаганда (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш) гамәлгә ашырыла.»;

6) 3.11 пунктында «рөхсәт бирелергә мөмкин» сүзләрен «рөхсәт бирелә» сүзләренә алыштырырга;

7) 3.13 пунктында «2 нче кушымта нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

8) 1 һәм 2 нче кушымталарны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (tukay.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе О.В. Сурова